РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**МУСЛЮМОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ГЛАВА МИТРЯЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЕТРӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

2 номерлы карар

Метрәй авылы

2026 ел «06»июль

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Метрәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Үрнәк торак пунктын бетерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында»**

Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге халкының Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Метрәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Үрнәк авылы торак пунктын бетерү мәсьәләсе буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында» Метрәй авыл җирлеге Уставы,нигезләмәсе белән,карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Метрәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Үрнәк торак пунктын бетерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

2. Әлеге карарны 2026 елның 7июльдан да соңга калмыйча Метрәй һәм Салауз-Мухан, Иске Чакмак, Ольгино авыллары җирлекләренең мәгълүмат стендларында, шулай ук Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Билгеләргә:

1) гавами тыңлауларны үткәрү вакыты-2026 елның 23 июль, 10.00 сәгатьтә;

2) үткәрү урыны-ТР, Мөслим районы, Метрәй авылы, Пушкин ур., 50 (Метрәй башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе МБГББУ бинасы)

3) фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырылырга мөмкин булган адрес: ТР Мөслим районы,Метрәй авылы, Пушкин урамы, 50, (эш көннәрендә -8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр)

4) 2026 елның 22 июльгә кадәр чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү срогы.

4.Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге башкарма комитетына «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» Метрәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Үрнәк авылы торак пунктын бетерү мәсьәләсе буенча Метрәй, Салауз-Мухан, Иске Чакмак, Ольгино авыллары халкы катнашында гавами тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә.

5. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Метрәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Үрнәк торак пунктын бетерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында» 2025 елның 8 августындагы 2 номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Мөслим муниципаль районы
Метрәй авыл җирлеге башлыгы

Шәмгунов И.В.